**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 25 февралендәге 578 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 17 августындагы 2039 номерлы карары белән расланган Комлы Кавал торак пунктыннан төньяктарак урнашкан Казан шәһәре территориясен планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьялары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, вәкаләтле Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына таянып, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 17 августындагы 2039 номерлы карары белән расланган Комлы Кавал торак пунктыннан төньяктарак урнашкан Казан шәһәре территориясен планлаштыру проектына, әлеге карарга кушымта нигезендә планлаштыру проектының аерым өлешләрен раслап, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның  25 февралендәге
578 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 17 августындагы 2039 номерлы карары белән расланган Комлы Кавал торак пунктыннан төньяктарак урнашкан Казан шәһәре территориясен планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләр**

IV «Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, территорияне план буенча үстерү характеристикалары, шул исәптән территориядәге төзелешнең тыгызлыгы һәм параметрлары, социаль, транспорт хезмәте күрсәтү һәм инженерлык-техник яктан тәэмин итү системаларын үстерү характеристикалары турында нигезләмә» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 6 бүлекчә өстәргә:

**«6. Урам-юл челтәре өчен алына торган җир кишәрлекләре турында белешмәләр**

| № т/б | Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Мәйданы, кв.м | Ясала торган җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төре | Мәҗбүри алу/резервлау |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 16:24:090704:5249 | 23001 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Өлешчә мәҗбүри алу |
| 2 | 16:24:090704:51 | 2900 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Мәҗбүри алу |
| 3 | 16:24:090704:4004 | 40418 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Тулысынча мәҗбүри алу» |

______________________